Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

08 ноябрь 2019 ел N 4

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Әлмәт авыл җирлеге
Яшьләр бистәсендә гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын
билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 23 ноябрендә, 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Яшьләр бистәсендәге Юл, Урман, Бакча, Кыр урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Яшьләр бистәсе, Мәктәп урамы, 3 нче йорт.

2. 2019 елның 24 ноябрендә, 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Яшьләр бистәсендәге Мәктәп, Комсомол урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Яшьләр бистәсе, Мәктәп урамы, 3 нче йорт.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл җирлегенең Яшьләр бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Яшьләр бистәсенең су алу скважинасын торгызу, сметалар төзү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Халык җыены этапларын мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Яшьләр бистәсе, Мәктәп урамы, 3 нче йорт.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Яшьләр бистәсендә сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Яшьләр бистәсе, Мәктәп урамы, 3 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми

порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Әлмәт авыл
җирлеге башлыгы

А.А. Веретенцев